КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 апрель г.Казань № 350

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) өстәмә кыйммәткә салым исәпләмичә, түбәндәге чараларны, шул исәптән «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты (алга таба таба – Федераль проект) кысаларында, чыгымнар өлешен каплауга федераль бюджеттан финансланучы субсидияләр (алга таба – субсидияләр, алучылар) бирү механизмын билгели:

а) авыл хуҗалыгы әйләнешенә җәлеп ителә торган төшеп калган авыл хуҗалыгы җирләрендә культуртехник чаралар, шул исәптән:

җирләрне агач һәм үлән үсемтеләреннән, түмгәкләрдән, агач төпләреннән һәм мүктән, шулай ук ташлардан һәм башка әйберләрдән чистарту;

туфракны йомшарту, комландыру, балчыкландыру, җирләү, плантаж һәм беренчел эшкәртү;

туфракның кислоталылыгын киметүче мелиорантлар кертү;

б) урман агромелиорациясе чаралары, шул исәптән:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр чикләре буенча саклагыч урман утыртмалары булдыру юлы белән җирләрне табигый, антропоген һәм техноген тискәре күренешләр йогынтысыннан саклау;

саклау урман утыртмалары булдыру юлы белән көтүлекләр җирләрен деградацияләүне булдырмау;

чокырларда, коры үзәннәрдә, комлыкларда, елга ярларында һәм башка территорияләрдә урман утыртмалары булдыру юлы белән җирләрне эрозиядән саклау;

в) гидромелиорация чаралары – гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы сугару һәм киптерү системаларын һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны, шулай ук милек (аренда) хокукында авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнеке булган балык үрчетүче буаларны төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазландыру, төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру бәясен җыелма сметалы исәпләүгә кертелгән (шул исәптән лизингка алынган) машиналар, җайланмалар, су сиптерү һәм сугару аппаратлары, насос станцияләре сатып алу, проект һәм эзләнү эшләрен үткәрү һәм (яки) әлеге объектларга карата проект документларын әзерләү белән бәйле чыгымнардан тыш.»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидияләр әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән чаралар кысаларында алучылар чыгымнарының бер өлешен (өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплау максатларында бирелә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алучылар субсидия алу өчен Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмәсе;

«Татарстан Республикасы буенча җирләрне мелиорацияләү һәм авыл хуҗалыгы су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең сугарулы кишәрлекне яисә гидротехник корылманы сугару системасының аерым өлешләренең техник характеристикалары буенча сугару җайланмаларын һәм сугару системасының урнашу схемаларын төзү яисә торгызу мөмкинлеге турында, шулай ук элек файдаланылмый торган җирләрне әйләнешкә кертү мөмкинлеге хакында бәяләмәсе, югары продуктлы азык җирләрен булдыру һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең авыл хуҗалыгы әйләнешеннән төшеп калуын булдырмау турында бәяләмәсе;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында гариза, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын, шул исәптән түбәндәге турында мәгълүмат күрсәтелгән:

субсидия алучы законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

субсидия алучы – юридик зат бетерү, банкротлык процессында түгел, ә субсидия алучы – шәхси эшмәкәр шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булып тормый;

субсидия алучы бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы түгел;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары юк;

субсидия алучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләүгә үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

субсидия алучы экспорт юнәлешле авыл хуҗалыгы продукциясен үстерү өчен мелиорацияләнә торган җирләрне гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы яңа мелиоратив системаларны реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру һәм төзү исәбенә файдалануга кертү яисә мәдәни-техник чаралар уздыру хисабына авыл хуҗалыгы продукциясен экспорт юнәлешле үстерү өчен авыл хуҗалыгы җирләрен әйләнешкә кертүне тәэмин итү (федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидияләр бирү очрагында) йөкләмәсен ала;

субсидия алучы мелиорацияләнә торган һәм субсидия биргән елдан соң килүче елда (Федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидия бирү очрагында) авыл хуҗалыгы җирләре әйләнешенә җәлеп ителгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә яңа товар масса булдыру хисабына агросәнәгать комплексы продукциясен (натураль чагылышта) җитештерергә һәм экспортка чыгарырга йөкләмә ала.

Субсидия алучылар үз инициативасы буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавын раслый торган салым органы белешмәсен тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документ авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан үз инициативасы буенча күрсәтелмәгән очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә салым органында соратып ала.

Федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидияләр алу максатында гаризада тиешле тамга ясала.»;

12 пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) субсидия алучы тарафыннан субсидия һәм башка хисап бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында Министрлык тарафыннан билгеләнгән хисап бирү тәртибе, формалары һәм сроклары;»;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

а) Федераль проект кысаларында субсидияләрдән тыш, культуртехник, агроурманмелиоратив һәм гидромелиоратив чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү өчен субсидияләр биргәндә:

гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы яңа мелиорация системаларын реконструкцияләү, техник яктан яңадан торгызу һәм төзү исәбенә мелиорацияләнә торган җирләрнең мәйданы;

агроурманмелиоратив чаралар үткәрү хисабына авыл хуҗалыгы җирләрен җил эрозиясеннән һәм чүлләнүдән саклау һәм саклап калу (утырту мәйданы);

культуртехник чаралар уздыру хисабына төшеп калган әйләнешкә җәлеп ителгән авыл хуҗалыгы мәйданы;

б) Федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидияләр биргәндә:

гидромелиоратив чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга:

экспорт юнәлешле авыл хуҗалыгы продукциясен үстерү өчен мелиорацияләнә торган җирләрнең мәйданы гомуми һәм шәхси файдаланудагы яңа мелиоратив системалар реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру һәм төзү исәбенә кертелгән;

культуртехник чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга:

культуртехник чаралар үткәрү исәбенә экспорт юнәлешле авыл хуҗалыгы продукциясен үстерү өчен әйләнешкә кертелгән төшеп калган авыл хуҗалыгы җирләрнең мәйданы;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә мелиорацияләнә торган һәм авыл хуҗалыгы җирләре әйләнешенә җәлеп ителгән яңа товар масса булдыру хисабына агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты күләме (табигый чагылышта) киләсе елга субсидия бирү елы өчен.

мелиорацияләнә торган һәм субсидия биргән елдан соң килүче елда авыл хуҗалыгы җирләре әйләнешенә җәлеп ителгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә яңа товар масса булдыру хисабына агросәнәгать комплексы продукциясе (натураль чагылышта) күләме.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин